ГЛАВА НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Молодежная, д.4,
с. Старое Русское Маматкозино, 422589

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр ур., 4 нче йорт,
Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы, 422589

Тел.: (84379) 33-6-31, факс: (84379) 33-6-31.

16.11.2020 № 1

На № ________ от ________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Татар Мәмәтхуҗасы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә, 2020нче елның 16нчыноябрендә узган «2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Татар Мәмәтхуҗасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым җыюга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча: - Татар Мәмәтхуҗасы авылы зиратына вак таш сатып алу һәм төзекләндерү, дигән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез риза булырсызмы, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 78 катнашучы, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан 42 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 42 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Татар Мәмәтхуҗасы авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

«2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Татар Мәмәтхуҗасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнардан тыш,1000 сум күләмендә үзара салым җыюга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча: - Татар Мәмәтхуҗасы авылы зиратына вак таш сатып алу һәм төзекләндерү, дигән

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез риза булырсызмы, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләрен танырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Татар Мәмәтхуҗасы авылында халык җыены нәтиҗәләрен Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В. В. Никитушкин